0+

Укыйбыз, сөйлибез, сөйләшәбез

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

Укыйбыз, сөйлибез, сөйләшәбез

Уку ярдәмлеге

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2017

УДК 372.3/.4
ББК 74.102
У38

Автор-төзүчесе *Николай Максимов*
Рәссамы *Светлана Ибраһимова*

У38 **Укыйбыз, сөйлибез, сөйләшәбез** : уку ярдәмлеге / [авт.-төз. Н. В. Максимов]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. – 31 б.
ISBN 978-5-298-03350-3

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары белән шөгыльләнер өчен әти-әниләргә, тәрбиячеләргә тәкъдим ителә торган бу кулланма Казан (Идел буе) федераль университеты доценты Николай Максимовның «Сөйләм калыпларына нигезләнеп, татар теленә өйрәтү технологиясе» (Татарстан китап нәшрияты, 2015) дигән фәнни-методик хезмәте буенча төзелде.

УДК 372.3/.4
ББК 74.102

ISBN 978-5-298-03350-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2017
© Максимов Н. В., 2017

ОЛЫЛАР КОЛАГЫНА БЕР СҮЗ

Баланың сөйләү һәм аралашу теле *кем? нәрсә? кайчан? кайсы? нинди? ничә? ничек? нәрсәдә? нишлим? нишләмим? нишлисең? нишләмисең? нишли? нишләми?* кебек сорау сүзләргә нигезләнеп формалаша.

Сөйләм сорау-җавап формасында гына бара алмый. Сөйләшүдә катнашучы затлар (**мин** һәм **син)** бер-берсенә һәм темадан чыгып оештырылган уртак сөйләм эчтәлегенә карата үз мөнәсәбәтен дә белдерә. Шул сәбәпле алар 1 нче зат – **мин** ролендә сорау биргәндә, *әйе* яки *юк* кебек сүз – җөмләләрдән, *гафу ит, әйт әле, беләсем килә, минемчә* яки *мин шулай уйлыйм, синеңчә* яки *син ничек уйлыйсың*; 2 нче зат – **син** ролендә җавап биргәндә, *рәхмәт, мин дә шулай уйлыйм, килешәм* һ. б. керешмәләрдән файдалана.

Сөйләмдә сорау җөмлә һәрвакыт 2 нче затка – **син** сүзенә карата гына кулланыла һәм аңа һәрвакыт исемен яки эндәш сүзләрне яки икесен дә (туганнарга – *бабай, әби, әти, әни, абый, апа, сеңлем, энем, матурым;* башкаларга – *якташ, авылдаш, классташ, дустым, кадерлем, күрше* һ. б.) әйтеп мөрәҗәгать итәргә кирәк. Сорау җөмлә ике төрле юл белән – *сорау сүз* яки *сорау кушымчасы* (*-мы/-ме, -мыни/-мени*) ярдәмендә ясала:

– *Син* ***кая*** *барасың*?
– *Мин* ***мәктәпкә*** *барам.*
– *Син мәктәпкә* ***кем белән*** *барасың*?
– *Мин* ***әнием белән*** *барам*. Син дә әниең белән барасың**мы**?!
– *Әйе, мин дә мәктәпкә* ***әнием белән*** *барам.*

Бала өйдә олылар сөйләшкән телгә ияреп, белгән кадәрле сорау һәм җавап сүзләрдән, хәтерендә калган сорау һәм җавап җөмлә калыпларыннан файдаланып, әкренләп, күргәннәре яки кемнәндер ишеткәннәре турында сөйләргә (*монолог – хикәя* төзергә) һәм, шул эчтәлеккә карата үз фикерен белдереп, аралашырга (*диалогта* катнашырга) өйрәнә.

Сөйләм 3 этапта формалаша. Бала белән аралашу ул – теманы аңлап, дөрес сөйләргә һәм сөйләшергә өйрәтү уены. Без аны кече яшьтән тормышка әзерләргә, лидер булырга өйрәтергә тиеш. Ул, беренчедән, 1 нче зат – **мин** вазифасын үтәргә өйрәнсен; икенчедән, 2 нче – тыңлаучы затлар белән сүз ярдәмендә идарә итәрлек, тормышта туган проблемаларны уңай хәл итә алырлык шәхес булып формалашсын.

ЧУЛПАНГА БӘЛЛҮ

Бәлли-бәлли, бәү итә,
Чулпан йокыга китә.
Чулпан йокыга киткәч,
Әнисе дә ял итә,
Әтисе дә ял итә,
Әбисе дә ял итә,
Бабасы да ял итә.

Чулпан йокыга киткәч,
Соры песи ял итә,
Чыпчыклар да ял итә,
Сандугач та ял итә,
Карлыгач та ял итә.

Бикә Рәхимова

Ка́йчан?	**Кем?**	**Ни́шли?**
Кичен	**Чулпан**	йокыга китә йокыга китә́ме?
Арыгач	**балалар** **Гүзәл** **Марат**	
Чулпан йокыга киткәч	әнисе, әтисе	йокларга ята
Балалар йоклагач	әбисе, бабасы	йокларга ята́мы?
Балалар йоклаганда	әтиләр әниләр бабайлар әбиләр апалар абыйлар	йоклый йоклы́ймы?
	елгалар, күлләр	ял итә ял итә́ме?
	песиләр, этләр	
	кошлар чыпчыклар тургайлар сандугачлар карлыгачлар	

ДУСЛЫК

Зәңгәр күк Кояш белән дус,
Иген – кыр белән,
Җәйләр – җылы яңгыр белән,
Чишмә – җыр белән.

Күлләр аккошлар белән дус,
Май – сирень белән,
Төн – якты йолдызлар белән,
Мин – синең белән.

Резеда Вәлиева



<table>
<tr><th>Нә́рсә?
Кем?</th><th>Нә́рсә нәрсә белән?
Кем кем белән?</th><th>Ни́чек?</th></tr>
<tr><td>3
Күк
Иген
Җәй
Чишмә
Күл
Май
Төн

Нәрсәдер</td><td>кояш
кыр
яңгыр
җыр
аккош
сирень
йолдыз

нәрсәдер
белән</td><td rowspan="4">дус

дус тү́гел

ду́смы?!

дус тү́гелме?

ду́смыни?!

дус тү́гелмени?!</td></tr>
<tr><td>1
Мин</td><td>малайлар, кызлар
апам, абыем
энем, сеңлем
белән</td></tr>
<tr><td>2
Син</td><td>апаң, абыең
энең, сеңлең
белән</td></tr>
<tr><td>3
Ул

Марат
Гүзәл

Ке́мдер</td><td>апасы, абыйсы
сеңлесе, энесе
белән

кем белә́ндер</td></tr>
</table>

«К» ЛАР ТУЛГАН БАКЧАГА!



Бу бакчага ни булган?!
Бакча «К» белән тулган:
Карлыган һәм кәбестә,
Кишер, карбыз һәм кабак;
Крыжовник һәм кукуруз;
Кыяр, кавын, кузгалак!..





Ә́йдә, рәхим и́тегез,
Авыз итеп ки́тегез!

Роберт Миңнуллин







Ке́мнең?	Ка́йда?		Ка́йсы?	Нәрсә?	Ни́шли?
1					
Безнең	бакчада		кызыл		үсә
	бакчабызда			карлыган	
2			ак	карбыз	
Сезнең	бакчагызда			кабак	үсә́ме?
3			кара	крыжовник	
Аларның	бакчасында	**та́гын**		кукуруз	
			сары	кыяр	
Маратларның				кавын	
Гүзәлләрнең			яшел	кузгалак	
				кәбестә	
Бабайларның				кишер	
Әбиләрнең					үсә?

МИН БА́РСЫН ДА БУЛДЫРАМ

Мин
Җил кебек
Улый беләм,
Яңгыр кебек
Елый беләм,
Кояш кебек
Көлә беләм,
Чишмә кебек
Җырлый беләм.

Агач булып
Шаулый алам,
Күгәрчендәй
Гөрли алам.
Бик тырышсам,
Балык кебек
Сөйлә́шми дә
Йөри алам.

Роберт Миңнуллин

Кем?	**Нә́рсә кебек?**	**Ни́шли?**
1 **Мин**	җил яңгыр кояш чишмә агач күгәрчен балык **кебек** **шикелле** **булып**	улый елый көлә җырлый шаулый гөрли сөйлә́шми дә йөри **беләм** **алам**
2 **Син**		белә́сеңме? ала́сыңмы?
3 **Ул** Марат Гүзәл **Ке́мдер**		белә́ме? ала́мы?

ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!

Әтәчтән дә иртәрәк
Уяндым мин, әлбәттә.
– Хәерле иртә, әннәм!
Хәерле иртә, әттәм!

Үзем урын җыям мин,
Үзем юына алам.
– Хәерле иртә, әбкәм!
Хәерле иртә, бабам!

Мәктәпкә үзем барам,
Кала́лар мине мактап.
– Хәерле иртә, апам!
Хәерле иртә, мәктәп!

Ләбиб Лерон



Ка́йчан?	Кем?	Ке́мгә?	Нә́рсә дип?	Нәрсә?	Ка́я?	Ни́шли?
Иртән	1 Мин	әниемә әтиемә	хәерле иртә!			әйтәм
Торгач		бабама әбиемә	хәерле кич!			җыям
Кичен	үзем	апама абыема				юынам
Йоклар алдыннан		энемә сеңлемә	тыныч йокы!	урын	бакчага мәктәпкә	барам
	2 Син	әниеңә әтиеңә				әйтә́сеңме? әйт
		бабаңа әбиеңә	дип			җыя́сыңмы? юына́сыңмы?
	үзең	апаңа абыеңа				җый, юын бар
		энеңә сеңлеңә				

БӘХЕТЛЕ КӨН

Дуслар, бу́ген ни́нди көн,
Сез белә́сездер, бә́лкем?
Бе́лмәсәгез, үзем әйтәм:
Бүген минем туган көн!

Резеда Вәлиева



МИН МАШИНА ЯРАТАМ

Миңа
Шу́ндый әйбәт бәйрәм –
Туган көн килде.
Әтием миңа
Бүләккә
Машина бирде.

Резеда Вәлиева

Ка́йчан?	Кем?	Ке́мгә?	Нә́рсә?	Ни́шләде?
Туган көнем җиткәч Туган көнемдә	әтием әнием әбием бабам апам абыем энем сеңлем дустым	**1** **миңа**	машина курчак китап телефон	бүләк итте
Туган көнең җиткәч Туган көнеңдә	әтиең әниең әбиең бабаң апаң абыең энең сеңлең дустың	**2** **сиңа**		бүләк итте? бүләк иттеме?
Туган көне җиткәч Туган көнендә	әтисе әнисе әбисе бабасы апасы абыйсы энесе сеңлесе дусты	**3** **аңа** Маратка Гүзәлгә		бүләк итте? иттеме? иттемени?! иткәнме?

АКЫЛЛЫ ТУП

Камил әйтә:
– Иң яхшы туп минеке,
Һәркем күрә!
Ул шундый тиз тәгәри һәм
Биеккәрәк сикерә!

Җәмил әйтә:
– Бөтен туп та
Тәгәри дә сикерә.
Ә минеке акыллырак:
Типкәч, капкага керә!

Хәнәфи Бәдигый

Кем?	Нә́рсә дип?	Ни́шли?
3 **Камил**	иң яхшы туп минеке	әйтә
Аның дусты	минем туп шу́ндый тиз тәгәри	мактана
	минем туп биеккәрәк сикерә	
Җәмил	минем туп акыллырак	
Ул (да)	минем туп, типкәч, капкага керә	
1 **Мин** (дә)		әйтәм мактанам
2 **Син** (дә)	**дип**	әйтә́сең әйтә́сеңме? мактана́сың мактана́сыңмы?

455

НИ́ЧӘ МӘЧЕ?

Әбиемнең мәчеләре
Тезелгәннәр, ка́рагыз,
Мин күрсәтәм, сез ка́рагыз...

Бергә-бергә са́нагыз:
– Ме́нә бусы –
Соры мәче,
Ме́нә бусы –
Сары мәче,
Ме́нә бусы –
Ак мәче!

Шәүкәт Галиев



Ке́мнең?	Нә́рсәсе?		Ни́чәү?	Ка́йсы?	Ни́нди?
1 Минем әбиемнең	мәчеләре	бар берә́ү икә́ү юк	берә́ү икә́ү өчә́ү	берсе икенчесе	зур кечкенә
2 Синең әбиеңнең	мәчесе	ба́рмы?		зурысы кечкенәсе	соры соры́мы?
3 Аның әбисенең Маратның әбисенең Гүзәлнең әбисенең		ю́кмы?			сары сары́мы? ак а́кмы? матур шаян

ҖИРДӘ МИҢА НИ КИРӘК?

Җирдә миңа ни кирәк? –
Әти дә әни кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк? –
Без яшәгән өй кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк? –
Туган, үскән ил кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк? –
Мәңге имин Җир кирәк!

Шәүкәт Галиев



<table>
<tr><th>Ка́йда?</th><th>Ке́мгә?</th><th>Ка́йсы?</th><th>Нә́рсә?</th><th>Кем?</th><th></th></tr>
<tr><td rowspan="3">Җирдә</td><td>1
миңа</td><td rowspan="3">без
туган

без
ягъни
мин
һәм энем
туган

без
үскән

без
яшәгән</td><td rowspan="3">ил

өй

тынычлык</td><td>әнием
әтием

әбием
бабам

апам
абыем

энем
сеңлем

дустым
дусларым</td><td rowspan="3">кирәк?

кирә́кме?

кирәк
тү́гелме?

кирәк</td></tr>
<tr><td>2
сиңа</td><td>әниең
әтиең</td></tr>
<tr><td>3
аңа
ягъни

Сашага
Гүзәлгә</td><td>әнисе
әтисе</td></tr>
</table>



НИ ӨЧЕН?

– Балаларга ник колак?
– Үсəргə́дер, иң матур
Сүзлəрне генə тыңлап.

– Ə күзлəребез ни́гə?
– Җирдəге гүзəллекнең
Һə́ммəсен дə күрергə.

– Аякларыбыз ни́гə?
– Гомер буе җирдəге
Юллар буйлап йөрергə.



– Ə кулларыбыз ни́гə?
– Безгə тиеш эшлəрнең
Бáрысын да эшлəргə.

– Ə башларыбыз ни́гə?
– Эшлəпəлəр, башлыклар
Һəм бүреклəр киярга.

Шая́ртмагыз, белə́сез,
Ю́ри генə көлə́сез:

Кирəк ул иртəн, кичен
Əйбəтлəп уйлар өчен!

Роберт Миңнуллин

Ке́мгә?	**Нә́рсә?**	**Ни́чек?**	**Ни өчен?**	
1 **Миңа**	колаклар		ишетер	кирә́кме?! кирәк
		дөрес	тыңлар	
	күзләр		күрер	
		матур	укыр	
	аяклар	тиз	йөрер	
			йөгерер	
		яхшы	сикерер	
2 **Сиңа**				кирәк?
	куллар	сизеп	эшләр	
			язар	кирәкме?
		тәмләп	ашар	
3 **Аңа**	борын	тырышып	иснәр	
Маратка Гүзәлгә	тел		сөйләшер чәйнәр	
Ке́мгәдер	баш		уйлар **өчен**	

ТОРМЫШКА КАРЫЙМ ДА...

Тормышка карыйм да сокланам,
Шатлыктан матур җыр көйли́мен.
Бар бит, дип куанам, минем дә
Үз илем, үз җирем, үз телем.

Ка́йларга барсам да, һә́рвакыт
Шулардан нур алып йөри́мен.
Ни булыр иде, дим, бу́лмаса
Үз телем, үз илем, үз җирем.

Шушы өч кыйммәткә алмашка
Һи́чнәрсә телә́ми күңелем.
Бе́ркемгә бирәчәк тү́гелмен
Үз җирем, үз телем, үз илем!

Шәмсия Җиһангирова

Кем?	Ка́йда?	Ни́гә?	Ни́чек?	Ни́шли?
1 **Мин**	җирдә илдә	үз илем үз телем әнием әтием **булганга**	горурланып шатланып	яшим
2 **Син**	өйдә	үз илең үз телең әниең әтиең **булганга**		яши́сең? яши́сеңме? я́шә!
3 **Ул** Әнием Әтиең Әбисе **Ке́мдер**		үз иле үз теле әнисе әтисе **булганга**		яши яши́ме? яшәсен!

КЫШ

Уянып, бү́ген иртән
Карасам тәрәзәгә,
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

Ә́йдәгез, тауга барыйк,
Чанада шуып калыйк.
Бер тузан юк, саф һава,
Җиргә ап-ак кар ява.

Җәвад Тәрҗеманов

<table>
<tr><th>Кем?</th><th>Ка́йчан?</th><th>Ка́я?</th><th>Нә́рсәдә?</th><th>Ни́гә?</th><th>Ни́шли?</th></tr>
<tr><td>1
Без
(дә)</td><td rowspan="3">бүген

дәрестән
соң

ял
көнендә

иртән
көндез
кичен</td><td rowspan="3">тауга

болынга

катокка</td><td rowspan="3">чанада

чаңгыда

тимераякта</td><td rowspan="3">шуарга

йөрергә</td><td>бара́бызмы?

бара́быз</td></tr>
<tr><td>2
Сез
(дә)</td><td>бара́сыз

бара́сызмы?

ба́рыгыз!</td></tr>
<tr><td>3
Алар
(да)</td><td>бара
бара́мы?

барсын!</td></tr>
</table>

ЯЗ КИЛӘ!

Гөрләвек ага,
Кояш елмая,
Торналар үтте
Тезелеп бая.

Гөрләвекләрдә
Уйный үрдәк, каз,
Илне яшәртеп,
Шаулап килә яз.

Нур Гайсин

МАЙ КИЛӘ!

Дөньяны яктыртып,
Кояшлы Май килә;
Йөзләрне балкытып,
Урамда Май көлә.

Роберт Миңнуллин

Ка́йчан?	Ка́йда?	Ни́чек?	Нәрсә?	Ни́шли?
Яз килгәндә	урамда			
			кояш	елмая елмая́мы?
Язын		шаулап		
			гөрләвек	ага ага́мы
Яз җиткәч				
	күктә	тезелеп		
			торналар кыр казлары аккошлар	
				кайта кайта́мы?
Май аенда				
			тургайлар сандугачлар	
				килә килә́ме?

ЯШЕЛЧӘЛӘР ҖЫРЫ



– Мин – бәрәңге – балаларның
Яраткан тәмле ашы.
– Мин – кәбестә, кешеләргә
Бик күп файда китерәм.



– Мин – чөгендер, баллырак,
Кешеләргә файдалырак.
– Яшелчәләрнең затлысы,
Иң татлысы мин – кишер.
– Су сибәргә ире́нмичә,
Ке́мнәр үстерә кыяр?
Җәй буе ашап кинәнер,
Калганын тозлап куяр.



– Ире́нмичә су сипсәгез,
Без мул булып үсә́рбез.
Көзләр җиткәч, түтәлләрдән
Өстәлләргә күчә́рбез.

Хәнәфи Бәдигый

* * *



Әни җәен кыяр тозлый,
Тәмле кайнатма ясый.
Ба́рыбыз да, кыш җиткәчтен,
«Җәй»не яратып «ашый».

Ленар Шәех

Ка́йчан?	Ка́йдан?	Ка́я?	Нә́рсә?	Ни́шли?
Көз җиткәч Көзен	бакчадан	йортларга	бәрәңге	кайтарыла кайтарыла́мы?
		кибетләргә	кәбестә	
Көз көннәрендә	яшелчә бакчасыннан	базарга	чөгендер	
		өстәлләргә	кишер	куела куела́мы?
Кыш җиткәч Кышын	кырдан	табынга	кыяр	
Кыш көннәрендә				

Методическое пособие

Для детей дошкольного и младшего школьного возраста

Автор-составитель **Максимов** Николай Валентинович

ЧИТАЕМ, ГОВОРИМ, РАЗГОВАРИВАЕМ

Казань. Татарское книжное издательство. 2017

На татарском языке

Уку ярдәмлеге

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Автор-төзүчесе **Максимов** Николай Валентинович

УКЫЙБЫЗ, СӨЙЛИБЕЗ, СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Мөхәррире *Э. Р. Хөснетдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректоры *Г. М. Хәбибуллина*

0+ Знак информационный продукции согласно ФЗ
от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.09.2017. Форматы 84×100 $^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 3,12. Тиражы 4000 д. Заказ А-2239.

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:

Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Маркетинг бүлеге:
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-кибет:
http://www.tatkniga.ru

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

9 785298 033503